РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.04.2019 ел № 12

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җирләү һәм җирләү эше турында" 12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 18 май, 196 нчы , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2010 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарлары нигезендә карар чыгарам:

1. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 5 946,47 (биш мең тугыз йөз кырык алты сум 47 тиен) сум күләмендә билгеләргә һәм №1, №2 кушымталар нигезендә гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” http//pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru.адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче М.И.Солтанов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Башкарма комитет карарына кушымта
«____» _________2019 № 1

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә жирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге**

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәтнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 50,00 |
| 2 | Табут һәм күмү өчен башка предметларны китерү | 4 018,75 |
| 3 | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 834,57 |
| 4 | Күмү(кабер казу) | 1 043,15 |
| 5 | Барлыгы | 5 946,47 |

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Башкарма комитет
карарына кушымта
«____» __________2019 № 2

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә**
**җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге**

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәтнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 50,00 |
| 2 | Тәнне кәфенләү | 834,57 |
| 3 | Табут һәм күмү өчен башка предметларны китерү | 3 184,18 |
| 4 | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 834,57 |
| 5 | Күмү(кабер казу) | 1 043,15 |
|  | Барлыгы | 5 946,47 |